| | |
|---|---|
| ГЛАВА КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.12.2021 г. Кошман ав. № 3

Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары төзү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары төзү тәртибен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм https://kushman-kaybici.tatarstan.ru/ веб – адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга,
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина

Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башлыгының
2021 ел «27» декабрь 3 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары төзү тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары төзү тәртибе (алга таба - Тәртип) җирлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары төзү максатларын, шартларын һәм процедурасын билгели.

2. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яки киңәшмә органнары (алга таба - координация яки киңәшмә органнары) түбәндәге максатларда оештырыла:

2.1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсе сәясәтен эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү.

2.2. Кошман авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны күтәрү һәм аларга ярдәм итү.

2.3. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга сала торган Кошман авыл җирлеге башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру.

2.4. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә өстенлекләрне билгеләгәндә, Кошман авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр әзерләү.

2.5. Гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен эшкуарлык эшчәнлегенә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга җәлеп итү һәм шушы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3. Координация яисә киңәшү органнары:

3.1. Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты.

3.2. Кошман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән (кече һәм урта эшкуарлык субъектыннан бер вәкил) һәм эшчәнлек алып баручы кимендә 10 кешедән торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары төркемнәре.

3.3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган коммерциягә карамаган оешма (алга таба - коммерциягә карамаган оешмалар) инициативасы буенча төзелергә мөмкин.

4. 3.2, 3.3 пунктчаларында күрсәтелгән координацион яки киңәшмә орган төзү инициаторлары (алга таба - инициаторлар) Кошман авыл җирлеге башлыгына тиешле язма мөрәҗәгать белән мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә координация яки киңәшмә органы составына тәкъдим ителә торган кандидатуралар күрсәтелергә тиеш.

5. Координация яисә киңәшмә орган  төзү турындагы мөрәҗәгатьне җирлек башлыгы карый. Мөрәҗәгатьне карау срогы 30 календарь көннән артык булырга тиеш түгел. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча инициаторларга җавап карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча язма рәвештә җибәрелә.

6. Координация яисә киңәшмә органын төзү, аның вәкаләтләрен билгеләү, сан ягыннан  һәм шәхси составы җирлек администрациясе карары белән раслана.

7. Координация яки киңәшмә орган төзү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга һәм Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.